Хәмидуллина, Р.  Якташ язучыбыз архивыннан / Р. Хәмидуллина // Заман сулышы. – 2025. –11 апрел. – Б. 9.

# Якташ язучыбыз архивыннан

**«Заман сулышы» газеты редакциясе белән Чаллы шәһәреннән Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, китапханәче Роза Хәмидуллина элемтәгә керде.**

Роза ханым әйтүенчә, безнең якташ язучыбыз Мәхмүт Газизовның шәхси архивын Яр Чаллы шәһәр үзәк китапханәсенең әдәбият тарихы музеена язучының хатыны — Нурсинә апа Газизовага тапшырган. Исегезгә төшерәбез: язучы, шагыйрь Мәхмүт Газизов Урдалыда туып-үсә. 1970-2013 елларда Чаллы шәһәрендә яшәгән, шунда җирләнгән. Китапханәче Роза ханым безгә — редакциягә язучының шәхси архивыннан табылган язмаларын, фотоларны җибәрде. Бик зур рәхмәт аңа.

*«Мәхмүт абый үзе еш кына шигырьләрен „Мәхмүш бабай“ тәхәллүсе белән вакытлы матбугат битләренә тәкъдим итә иде. Мена сезгә аның 1994 елда язылган шаян шигырен тәкъдим итәм»*, — ди Роза Хәмидуллина.

## Мәхәббәт

***Ниләр булмый бу дөньяда!***
***Кара инде, күр әле:***
***Чын-чынлап Су анасына***
***Гашыйк булган... Шүрәле!***

***Бер чак таңда күл гүзәле***
***Су коенган чагында***
***Шүрәле агач артыннан***
***Күреп торган барын да...***

***Шул мәлдән «урман сарыгы»***
***Мәҗнүннән дә уздырган. –***
***Йөрәге купкан, Сусылу***
***Аның күзен екыздырган.***

***Күңелендә бер бөртек тә***
***Усаллыгы калмаган.***
***Калыр иде – җанын-тәнен***
***Сөю уты ялмаган.***

***Үрсәләнә, борсалана***
***Әллә нишләмәк була;***
***Кызның ефәк сачкәйләрен***
***Үбеп иснәмәк була;***

***Нечкә сиртмә билкәйләрен***
***Сыйпап, тотмакчы була.***
***«Кети-кети»***
***иткән шәпкә***
***Кысып кочмакчы була...***

***Су анасы да хәйләкәр,***
***Ни әйтсәң дә – хатын-кыз;***
***Юри кызыктырып йөзә, -***
***Шүрәле бит хатынсыз.***

***Миңа да гыйшык***
***тоталар***
***Дип шатлана, сөенә;***
***Тарагын урлап китсәң дә,***
***Эзләп килмәс өеңә.***

***Зыян салмый адәмнәргә,***
***Батырам дип сөйләнми;***
***Балык тоткан***
***малайларны***
***Күл төбенә сөйрәми.***

***Сөю-мәхәббәт һәр затны***
***Меңгә үзгәртә икән.***
***Начар холык-фигыльне дә***
***Ипли, төзәтә икән.***

***Әй Шүрәле, мөкиббән җан***
***Су анасы гүзәлгә!***
***Парлашып су коенмакчы,***
***Өйрәнәм, ди, йөзәргә...***

***Кытыкламый,***
***туктады гел***
***Кешеләргә тиюдән;***
***Яр буеннан китә алмый, –***
***Башы чыкмый сөюдән.***



**Язмаларны Розалия Мостафина әзерләде.**